ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.01.2022 с.Старое Дрожжаное № 37

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Кәкерле авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын эшләү турында

Территорияне тотрыклы үстерүне, әйләнә-тирә мохитне саклауны тәэмин итү, территорияләрне планлаштыру, физик һәм юридик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү, инвестицияләр җәлеп итү өчен шартлар тудыру максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8 статьясындагы 1 пунктына, 30, 31, 32 статьяларына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14, 15 статьяларына, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 31 декабрендәге 507-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының 2018 елның 09 гыйнварындагы 10 номерлы боерыгына таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Кәкерле авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын эшләүгә керешергә.
2. 1 нче кушымта нигезендә шәһәр төзелешен зоналаштыру этапларын билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Кәкерле авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү эшләрен башкару тәртибен һәм вакытларын расларга (2 нче кушымта)
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) вакыттан үз көченә керә.
5. Әлеге карарны «Туган як» район газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга

(https://drogganoye.tatarstan.ru).

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары И.С. Бикчуровка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Д.А. Сатдинов

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның "21" 01 № 37
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Кәкерле авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләгәндә шәһәр төзелешен зоналаштыру этаплары**

1 нче этап - территориянең гамәлдәге торышын анализлау, җирдән файдалану һәм территориядән файдалану өчен махсус шартлар белән билгеләнгән җир кишәрлекләре чикләрен исәпкә алып, башлангыч мәгълүматлар җыю (саклау, санитар-яклау зоналары, минималь ара зоналары, санитар разрывлар, су саклау зоналары, эчә торган су чыганакларын санитар саклау зоналары), җирлекнең үсеш программалары;

2 нче этап - җирлек территориясендә булган һәм планлаштырылган республика һәм федераль әһәмияттәге объектларны анализлау;

3 нче этап - территориаль зоналар чикләрен формалаштыру буенча тәкъдимнәр эшләү.

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның "21" 01 № 37
карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Кәкерле авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре (алга таба-ПЗЗ) проектын әзерләү буенча эшләр үткәрү тәртибе һәм вакытлары**

| № т/б | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен әзерләү буенча эшләр үткәрү тәртибе | Эшләрне үткәрү вакыты | Башкаручы, җаваплы зат |
|---|---|---|---|
| 1 | ПЗЗ проектын әзерләү турында Карар кабул итү | 2022 елның гыйнваре | Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет) |
| 2 | ПЗЗ проектын әзерләү турындагы Карарны бастырып чыгару | Кабул ителгән вакыттан алып 10 көн эчендә | Башкарма комитет |
| 3 | Физик һәм юридик затлардан ПЗЗ проекты буенча тәкъдимнәр кабул итү | Подряд шартнамәсе буенча проектлана башлаганчы, әмма ПЗЗ проектын әзерләү турындагы карар басылып чыккан көннән бер айдан да ким булмаган вакыт эчендә | Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы авыл җирлекләренең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектларын әзерләү комиссиясе (алга таба - Комиссия) |
| 4 | ПЗЗ проектын әзерләү эшләрен башкару | Подряд шартнамәсе нигезендә | Комиссия |
| 5 | ПЗЗ проектын тикшерү үткәрүне техник регламентларның, җирлекне, муниципаль районны, Татарстан Республикасын, Россия Федерациясен территориаль планлаштыру документларының туры килүенә тәэмин итү | 7 көн дәвамында | Башкарма комитет |
| 6 | Иске Кәкерле авыл җирлеге башлыгы экспозиция өчен | Тикшерү нәтиҗәләре буенча уңай | Комиссия |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | ПЗЗ проектын һәм материалларны җибәрү | килешүдән соң 5 көн эчендә | |
| 7 | ПЗЗ проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру турында карар кабул итү | ПЗЗ проектын алганнан соң 10 көн дәвамында | Иске Кәкерле авыл җирлеге башлыгы |
| 8 | Гавами тыңлауларын үткәрү турында карар бастырып чыгару | Кабул ителгән вакыттан алып 10 көн эчендә | Иске Кәкерле авыл җирлеге башлыгы |
| 9 | ПЗЗ проекты материаллары экспозициясен ачу | 7-нче этап тәмамланганнан соң 2 көн эчендә | Иске Кәкерле авыл җирлеге башлыгы |
| 10 | ПЗЗ проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү | 8-нче этап тәмамланганнан соң, кимендә бер һәм өч айдан да ким булмаган вакыт эчендә. | Иске Кәкерле авыл җирлеге башлыгы |
| 11 | Гавами тыңлаулар беркетмәсен әзерләүне тәэмин итү һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәләр бастырып чыгару | Гавами тыңлаулар үткәргәннән соң 10 көн эендә | Иске Кәкерле авыл җирлеге башлыгы, Комиссия |
| 12 | ПЗЗ проекты, беркетмә һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча Башкарма комитетка тәкъдимнәр әзерләү һәм җибәрү | 2 көн дәвамында | Комиссия |
| 13 | ПЗЗ проектын Чүпрәле муниципаль районы Советына җибәрү | 5 көн дәвамында | Башкарма комитет |
| 14 | Чүпрәле муниципаль районы Советы тарафыннан ПЗЗ проекты буенча карар кабул итү | Чүпрәле муниципаль районы Советының чираттагы сессиясендә | Чүпрәле муниципаль районы Советы |
| 15 | ПЗЗ проекты буенча карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгару | Раслаганнан соң 10 көн эчендә | Чүпрәле муниципаль районы Советы |